РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки
муниципаль районы
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 24 нче апреле 172 №

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башкарма комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү Тәртибен раслау турында**

2006 елның 2 маендагы "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 2006.02.05. 59 - ФЗ №), 2003 елның 12 маендагы "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, РФ Президентының 2017 елның 17 апрелендәге "Гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләренә мониторинг һәм анализ ясау турында" 171 номерлы әмере, 2006 елның 4 маендагы "Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында" 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү Тәртибен расларга. (Алга таба - Тәртип)

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" бастырып чыгарырга һәм Әлки муниципаль районының рәсми alkeevski.tatarstan.ru сайтында халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге начальнигына йөкләргә.

Җитәкче: И.В.Юсупов

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020.24.04.
172 N Карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү Тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү Тәртибе (алга таба - Тәртип) 2006 елның 2 маендагы "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 59-ФЗ номерлы Федераль закон(алга таба - 2006.02.05. 59 - ФЗ №), 2003 елның 12 маендагы "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, 2014 елның 24 июлендәге "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 75-ЗРТ номерлыТатарстан Республикасы Законы, 2006 елның 4 маендагы "Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында" 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе гражданы (алга таба шулай ук - граждан) тарафыннан үзенә беркетелгән җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хокукын гамәлгә ашыруга бәйле хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала, шулай ук Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе билгели.

1.3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карауның билгеләнгән тәртибе гражданнарның барлык мөрәҗәгатьләренә дә кагыла.

1.4. Тәртип Әлки муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырыла.

## 2. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр

2.1. Граждан мөрәҗәгате (алга таба-мөрәҗәгать) - җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә юлланган тәкъдим, гариза яки шикаять, шулай ук гражданның дәүләт органына, җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгате;

2.2. тәкъдим - законнарны һәм башка норматив хокукый актларны, җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерү, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне үстерү, дәүләт һәм җәмгыять эшчәнлегенең социаль-икътисадый һәм башка өлкәләрен яхшырту буенча гражданның тәкъдимнәре;

2.3. гариза - гражданның аның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен яисә башка затларның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруда ярдәм итү турындагы үтенече яки законнарны һәм башка норматив хокукый актларны бозу, җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар эшендә кимчелекләр, яки күрсәтелгән органнарның һәм вазыйфаи затларның эшчәнлеген тәнкыйтьләү турында хәбәре;

2.4. шикаять - гражданинның бозылган хокукларын, ирекләрен яки законлы мәнфәгатьләрен йә башка затларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу яисә яклау турында үтенеч;

2.5. вазыйфаи зат-даими, вакытлыча яисә махсус вәкаләт буенча хакимият вәкиленең функцияләрен башкаручы яки җирле үзидарә органында оештыру-боеру, административ хуҗалык функцияләрен башкаручы зат.

2.6. коллектив мөрәҗәгать астында ике яки аннан күбрәк гражданның мөрәҗәгате, гражданнар берләшмәләре, шул исәптән юридик затлар берләшмәсе, шулай ук тавыш бирү яисә митингта катнашучыларның имзаларын җыю юлы белән кабул ителгән мөрәҗәгать аңлашыла.

## 3. Гражданнарның мөрәҗәгать итү хокукы

3.1. Гражданнар шәхсән мөрәҗәгать итәргә, шулай ук, гражданнар берләшмәләренең мөрәҗәгатьләрен дә кертеп, индивидуаль һәм коллектив, шул исәптән халык алдында әһәмиятле функцияләрне гамәлгә ашыру вазыйфасы йөкләнгән юридик затларга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм аларның вазыйфаи затларына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә һәм башка оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына мөрәҗәгатьләр җибәрергә хокуклы.

3.2. Гражданнар мөрәҗәгать итү хокукын ирекле һәм ихтыяри рәвештә гамәлгә ашыралар. Гражданнарның мөрәҗәгать итү хокукын гамәлгә ашыру башка затларның хокукларын һәм ирекләрен бозмаска тиеш.

3.3. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау бушлай башкарыла.

## 4. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карауга бәйле хокук мөнәсәбәтләрен хокукый җайга салу

4.1. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерүгә бәйле хокукый мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясенең халыкара килешүләре, федераль конституциячел законнары, әлеге Тәртип белән җайга салына.

4.2. Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары гражданнарның мөрәҗәгать итү хокукын яклауга юнәлдерелгән нигезләмәләрне билгеләргә, шул исәптән әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән гарантияләрне тулыландыручы мөрәҗәгатьләргә гражданнарның хокуклары гарантияләрен билгеләргә. мөмкин.

## 5. Мөрәҗәгатьне караганда гражданның хокуклары

Җирле үзидарә органы яисә вазыйфаи зат тарафыннан мөрәҗәгатьне караганда граждан хокуклы:

1) өстәмә документлар һәм материаллар тапшырырга яки аларны соратып алу турында, шул исәптән электрон формада мөрәҗәгать итәргә;

2)әгәр дә бу башка затларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылмаса һәм әгәр күрсәтелгән документларда һәм материалларда дәүләт яисә федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр булмаса мөрәҗәгатьне карауга кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышырга;

3)мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча, 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында күрсәтелгән очраклардан тыш, язмача җавап, язма мөрәҗәгатьне дәүләт органына,җирле үзидарә органы яисә мөрәҗәгатьләрдә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә бирелгән вазыйфаи затка күчерү турында хәбәрнамә алырга;

4) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә мөрәҗәгатьне карауга бәйле рәвештә мөрәҗәгать итү буенча кабул ителгән карарга яисә гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаять белән мөрәҗәгать итәргә;

5) мөрәҗәгатьне карауны туктату турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә.

## 6.Гражданның мөрәҗәгатенә бәйле иминлек гарантияләре

6.1. Гражданны җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка күрсәтелгән органнарның яисә вазыйфаи затның эшчәнлеген тәнкыйтьләп яки үз хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яки башка затларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу яисә яклау максатларындагы мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә эзәрлекләү тыела.

6.2. Мөрәҗәгатьне караганда мөрәҗәгатьтәге мәгълүматларны, шулай ук гражданның шәхси тормышына кагылышлы мәгълүматларны аның ризалыгыннан башка фаш итү рөхсәт ителми. Җирле үзидарә органына яисә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән вазыйфаи затка җибәрелгән язмача мөрәҗәгать мөрәҗәгатьтәге белешмәләр таратылмый.

## 7. Мөрәҗәгатьләргә карата таләпләр

7.1. Граждан язма, электрон, телдән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

7.2. Граждан үзенең язмача, электрон мөрәҗәгатендә мәҗбүри тәртиптә мөрәҗәгать җибәрелүче дәүләт органы яки җирле үзидарә органы исемен, яисә тиешле вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, яки тиешле затның вазыйфасын, шулай ук үзенең фамилиясе, исеме, атасының исемен (соңгысы - булган очракта), җавап җибәрелергә тиешле почта адресын, электрон адресын (булган очракта), мөрәҗәгатьләрне яңадан адреслау турында хәбәрнамәне мәҗбүри рәвештә күрсәтә, тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын бәян итә. Язма мөрәҗәгатьтә шәхси имзасын һәм датаны куя.

7.3. Дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать әлеге Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта), җавап электрон документ рәвешендә җибәрелергә тиеш булса, электрон почта адресын, һәм җавап язмача җибәрелергә тиеш булса, почта адресын мәҗбүри тәртиптә күрсәтә. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон формада теркәргә яисә күрсәтелгән документларны һәм материалларны яисә аларның күчермәләрен язма рәвештә җибәрергә хокуклы.

7.4. Кирәк булган очракта, үз дәлилләрен раслау өчен, граждан язма, электрон мөрәҗәгатькә документларны һәм материалларны яки аларның күчермәләрен кушып бирә.

7.5. Гражданнар Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, туган телендә яисә Россия Федерациясе халыкларының теләсә кайсы башка телендә тәкъдимнәр, гаризалар, шикаятьләр белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Сораулар, тәкъдимнәр, гаризалар, шикаятькә җаваплар

гражданнар мөрәҗәгать иткән телдә бирелә. Мөрәҗәгать телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

7.6. Әгәр язма мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгать җибәргән гражданның фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән булса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, эшләнә торган яки бөтенләй хокукка каршы гамәл, шулай ук аны әзерли торган, гамәл кыла торган яки кылган зат турында белешмәләр булса, мөрәҗәгать аның компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

7.7. Әгәр язма мөрәҗәгать тексты укырлык булмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул аның компетенциясе нигезендә органга яисә вазыйфаи затка каралуга җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгать теркәлгән көннән җиде көн эчендә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укылырлык икән, мөрәҗәгать җибәргән гражданга хәбәр ителә.

7.8. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен тапшыруның югарыда санап үтелгән тәртибе белән беррәттән органга, вазыйфаи затка мөрәҗәгать телеграмма яки факсималь элемтә аша тапшырылырга мөмкин. Күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр 2014 елның 24 июлендәге "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында "Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

## 8. Мөрәҗәгатьне карауга кабул итү мәҗбүрилеге

8.1. Әлки муниципаль районы органына яисә вазыйфаи затына кергән мөрәҗәгать, аларның компетенциясе нигезендә, мәҗбүри рәвештә теркәлергә һәм карап тикшерелергә тиеш.

8.2. Кирәк булган очракта мөрәҗәгатьне карый торган орган яисә вазыйфаи зат аны карап тикшерүне урынга чыгып тәэмин итә ала. Урынга чыгып мөрәҗәгатьне карауны оештыру тәртибе, шул исәптән аны үткәрү сроклары, органнарның норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

## 9. Вәкаләтләре туктатылган вазыйфаи затка адресланган граждан мөрәҗәгатьләрен карау

9.1. Гражданның әкаләтләре туктатылган вазыйфаи затка адресланган мөрәҗәгате күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру йөкләнгән вазыйфаи зат тарафыннан карала.

9.2. Мөрәҗәгатьне теркәү мәҗбүри.

## 10. Язма мөрәҗәгатьне теркәү һәм җибәрү

10.1. Граждан язма мөрәҗәгатьне мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган органга яисә вазыйфаи затка турыдан-туры җибәрә.

10.2. Язма мөрәҗәгать органга яисә вазыйфаи затка кергәннән соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегендә мәҗбүри теркәлергә тиеш.

10.3. Җитәкче резолюциясе белән күрсәтелгән, ләкин орган яисә вазыйфаи зат компетенциясенә керми торган мәсьәләләрне үз эченә алган язма мөрәҗәгать, теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә, әлеге Тәртипнең 7 пунктындагы 7.7 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш, мөрәҗәгать җибәргән гражданга, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында

хәбәрнамә җибәрелеп, мөрәҗәгатьләрдә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керүче органга яисә тиешле вазыйфаи затка юнәлдерелә

10.4. Язма мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү берничә орган яисә вазыйфаи зат компетенциясенә керсә, мөрәҗәгатьнең күчермәсе теркәлгәннән соң җиде көн эчендә тиешле органнарга яисә тиешле вазыйфаи затларга җибәрелә.

10.5. Язма мөрәҗәгатьне башка органга яисә башка вазыйфаи затка карауга җибәргәндә, кирәк булган очракта, күрсәтелгән органнардан яисә вазыйфаи заттан язма мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре турында документларны һәм материалларны соратып алырга мөмкин.

10.6. Шикаятьне карары яисә гамәл кылуы (гамәл кылмавы) дәгъва белдерелгән органга яисә вазыйфаи затка карау өчен җибәрү тыела.

10.7. Әлеге статьяның 10.6 өлешендә каралган тыю нигезендә мөрәҗәгатьләрдә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керүче орган яисә вазыйфаи затка карау өчен шикаять җибәрү мөмкин булмаган очракта, гражданинга аның тиешле карарга шикаять бирү хокукын аңлату белән шикаять кире кайтарыла яисә билгеләнгән тәртиптә гамәл кылу (гамәл кылмау) судка җибәрелә.

10.8. Электрон рәвештә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр әлеге Тәртипнең 10 пункты белән тәңгәл рәвештә теркәлә һәм җибәрелә.

## 11. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау сроклары

11.1. Мөрәҗәгатьләрнең барлык төрләре-органга яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә килгән шәхси һәм коллектив мөрәҗәгатьләр язма мөрәҗәгать теркәлгән көннән соң 30 көн эчендә карала.

11.2. Аерым очракларда, шулай ук әлеге Тәртипнең 10 пунктындагы 1 өлешендә каралган мөрәҗәгать җибәргән очракта, орган җитәкчесе, вазыйфаи зат яки вәкаләтле зат мөрәҗәгатьне карау срогын мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга карау срогын озайту турында хәбәр итеп, 30 көннән дә артык озайтырга хокуклы.

## 12.Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау белән бәйле рәвештә органнарга яки вазыйфаи затларга билгеле булган мәгълүматларны таратмау

12.1. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен караганда, мөрәҗәгать итүченең ризалыгыннан башка, аның шәхси тормышы турында мәгълүматлардан файдалану һәм тарату тыела, шулай ук аның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, яшәү урыны, эш яки уку урыны турында мәгълүматларны тарату рөхсәт ителми.

12.2. Мөрәҗәгатьне караганда мөрәҗәгатьтәге мәгълүматларны тарату рөхсәт ителми. Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләре булган органга яисә вазыйфаи затка җибәрелгән язмача мөрәҗәгатьләрдәге белешмәләр таратылмый.

## 13. Язма дәлилләрне тапшыру бурычы

13.1. Мөрәҗәгатьне караучы орган яисә вазыйфаи зат таләбенә билгеләнгән тәртиптә юнәлтелгән орган яисә вазыйфаи зат, мөрәҗәгатьләрне карау өчен кирәкле документларны

һәм материалларны, дәүләт серен яисә федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче һәм бирү өчен аерым бер тәртип билгеләнгән белешмәләр булган документлар һәм материаллардан тыш, 15 көн эчендә бирергә тиеш.

13.2. Таләп ителә торган дәлилләрне анлы рәвештә тапшырмауда гаепле вазыйфаи затлар законнар нигезендә җаваплы.

## 14. Гражданнарны шәхси кабул итүне оештыру

14.1. Органнарда гражданнарны шәхси кабул итү вәкаләтле затлар тарафыннан үткәрелә:

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарлары;

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе.
Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге начальнигы ;
Инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы (архитектор);

Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты ГХАТ бүлеге начальнигы;

Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты архив начальнигы;

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының торак төзү һәм субсидияләү бүлеге начальнигы ;

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы;

14.2. Органнарда гражданнарны шәхси кабул итүне оештырганда "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"Федераль закон белән билгеләнгән гражданнарны шәхси кабул итү тәртибенә карата таләпләр исәпкә алына.

14.3. Кабул итү һәр сишәмбе 8.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр вәкаләтле затлар тарафыннан үткәрелә. Белешмәләр өчен телефон: 8(84346)21-7-60

Кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр, гражданнарны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи затларның контакт телефоннары турында мәгълүмат гражданнарга массакүләм мәгълүмат чаралары һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, ТР, Әлки муниципаль районы ,Базарлы Матак авылы,Крайнов урамы 56 йорт адресында урнашкан район Советы һәм Башкарма комитеты бинасындагы мәгълүмати стендларда җиткерелә.

14.4. Кабул итүгә язылган һәр гражданга шәхси кабул итү карточкасы (1 нче кушымта) тутырыла, анда күрсәтелә:

1) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме;

2) яшәү урыны адресы;

3) кабул итүне алып баручы вазыйфаи затның фамилиясе;

4) мөрәҗәгатьнең кыскача эчтәлеге

5) башка кирәкле белешмәләр.

6) мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре;

7) телдән җавапка ризалык (яки ризасызлык).

Гражданнарны шәхси кабул итү карточкасы гражданнарны кабул иткән вазыйфаи зат тарафыннан имзалана.

14.5. Шәхси кабул итү вакытында гражданин шәхесне раслаучы документ күрсәтә.

14.6. Телдән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар һәм хәлләр ачык һәм өстәмә тикшерү таләп итмәгән очракта, гражданның ризалыгы белән мөрәҗәгать итүгә җавап кабул итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат тарафыннан, шәхси кабул итү карточкасында язма теркәлеп, телдән бирелергә мөмкин. Калган очракларда мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап бирелә.

14.7. Шәхси кабул итү барышында кабул ителгән язма мөрәҗәгать теркәлә һәм "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль законда һәм әлеге Тәртиптә билгеләнгән тәртиптә карала.

14.8. Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда беренче чираттагы шәхси кабул итү хокукына ия:

а) I, II төркем инвалидлар һәм (яки) аларның законлы вәкилләре (уллыкка алучы ата - аналарның берсе, опекун яки тәрбияләүче);

б) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясенең Хезмәт Геройлары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары;

в) инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затлар, шулай ук мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүче аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре;

г) өч яшькә кадәрге балалар белән кабул итүгә килгән гражданнар.

14.9. Әлеге пунктның 14.9 өлешендәге а-г пунктларында күрсәтелгән гражданнар шәхсән кабул итү вакытында, аларны беренче чиратта шәхси кабул итүгә хокукын раслаучы документ күрсәтәләр.

14.10. Органнар җитәкчеләре беренче чираттагы шәхси кабул итүгә хокукы булган гражданнарның өстәмә категорияләрен билгели алалар.

14.11. Бер үк вакытта беренче чираттагы шәхси кабул итү хокукына ия берничә граждан булса, гражданнарны кабул итү аларның килү тәртибендә гамәлгә ашырыла.

## 15. Шикаять бирү хокукы

Тәкъдиме, гаризасы, шикаяте буенча кабул ителгән карар белән килешмәгән граждан, бу карарга карата шул органга яки органга турыдан-туры буйсынган вазыйфаи затка яисә дәгъвалана торган карар кабул иткән вазыйфаи затка яки судка шикаять белдерү хокукына ия.

## 16.Орган һәм вазыйфаи затның гариза карау буенча бурычлары

Гаризада куелган мәсьәләләрне карау компетенциясенә кергән орган һәм вазыйфаи зат бурычлы:

1)гаризаны асылда законда билгеләнгән срокларда карарга;

2) граждан гаризасы буенча элек кабул ителгән карарларның үтәлешен исәпкә алырга;

3) нигезле карар кабул итәргә һәм аның үтәлешен тәэмин итәргә,

4) гариза биргән гражданга гаризаны карау нәтиҗәләре һәм аның буенча кабул ителгән карарны законнарда билгеләнгән вакытта хәбәр итәргә;

5) гаризада бәян ителгән таләпләрне канәгатьләндермәгән очракта, язма рәвештә гариза биргән гражданинның мәгълүматына, баш тарту сәбәпләрен җиткерергә, шулай ук гариза буенча кабул ителгән карарга карата шикаять бирергә мөмкин булган органны яисә вазыйфаи затны күрсәтергә.

## 17. Мөрәҗәгатьне караганда гражданның хокуклары

Орган яисә вазыйфаи зат тарафыннан мөрәҗәгатьне караганда граждан хокуклы:

1) мөрәҗәгатьне карый торган затка дәлилләрне шәхсән бәян итәргә;

2) органның тиешле структур бүлекчәсендә яисә тиешле вазыйфаи заттан телдән (шул исәптән телефон аша) яки язма мөрәҗәгатьне теркәү, шулай ук аны карау сроклары турында электрон рәвештә мәгълүмат алырга;

3) граждан тарафыннан бирелгән язма мөрәҗәгатьнең икенче нөхсәсендә бирелгән датасын, мөрәҗәгатьне кабул иткән органның вәкаләтле затының (вазыйфаи зат) фамилиясен һәм инициалларын күрсәтеп, имза салу юлы белән кабул итү фактын таныклавына;

4) өстәмә документлар һәм материаллар тапшырырга яки аларны соратып алу турында, шул исәптән электрон формада мөрәҗәгать итәргә;

5) язма гариза буенча әгәр бу башка затларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылмаса, күрсәтелгән документларда һәм материалларда федераль закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр булмаса, мөрәҗәгатьне карап тикшерүгә кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышырга;

6) мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең ,"Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль законның 11 статьясында күрсәтелгән очраклардан тыш, асылы буенча язмача җавап, язма мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган органга яисә вазыйфаи затка яңадан адреслау турында хәбәрнамә алырга;

7)мөрәҗәгать итү буенча кабул ителгән карарга яисә гамәлләргә (гамәл кылмауга) мөрәҗәгатьне Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә карауга бәйле шикаять белән мөрәҗәгать итәргә;

8) мөрәҗәгатьне карауны туктату турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә;

9) мөрәҗәгать буенча кабул ителгән карарга шикаять бирергә;

10) вәкил хезмәтеннән файдаланырга;

11)законнарда билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгатьне караганда органның яисә вазыйфаи затның законсыз гамәлләре (гамәл кылмаулары) нигезендә китерелгән зыянны каплатуга һәм мораль зыянны компенсацияләүгә.

## 18. Органнарның гражданнардан "турыдан-туры линия" һәм "кайнар линия" телефоннары буенча кабул ителгән мөрәҗәгатьләрен карау

18.1. Органнар, гражданнарның үз эшчәнлекләре турында мәгълүмат алуга хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итү, шулай ук гражданнарның мөрәҗәгатьләрен кабул итү өчен, "турыдан-туры линия" һәм "кайнар линия"эшен оештыра алалар.

18.2. Органнар тарафыннан "турыдан-туры линия" һәм "кайнар линия" телефоннары буенча кабул ителгән мөрәҗәгатьләр РФ һәм ТР законнары һәм әлеге Тәртип белән билгеләнгән срокларда теркәлергә тиеш.

18.3. "Турыдан-туры линия" һәм "кайнар линия" телефоннары буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен кабул итүгә вәкаләтле органның вазыйфаи заты, гражданның мөрәҗәгатен терки, контактлы телефон һәм (яисә) электрон почта адресын (булган очракта), мәсьәләнең асылы, мөрәҗәгать керү датасы һәм вакытын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең электрон карточкасын формалаштыра.

18.4. Электрон карточкадагы белешмәләр мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә ия булган органнарга җибәрелә.

18.5. "Турыдан-туры линияләр" һәм "кайнар линияләр" эше органнар кабул иткән норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 19. Гражданнарның күмәк мөрәҗәгатькә язмача җавап алу хокукына өстәмә гарантияләр

19.1. Гражданнарның күмәк мөрәҗәгатенә язма җавап, җавап алучы буларак мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән затка яки мөрәҗәгатькә кул куйган гражданнар коллективы вәкиленә җибәрелә.

19.2. Әгәр коллектив мөрәҗәгатьтә җавап алучы билгеләнмәгән булса, мөрәҗәгать итүчеләр исемлегендә яшәү урынын күрсәткән беренче гражданга җибәрелә.

19.3. Коллектив мөрәҗәгатькә җавап җибәрү турындагы үтенеч берничә мөрәҗәгать итүче (кул куелган) зат тарафыннан белдерелгән очракта, җавапның күчермәсе аларның һәркайсына күрсәтелгән почта адреслары буенча җибәрелә.

## 20.Коррупциягә каршы юнәлешле фактлар буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау

20.1. 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы тору турында" 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 2006 елның 4 маендагы "Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында" 34-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

гражданнар коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләрне органнарга җибәрергә хокуклы.

20.2. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре үз эченә коррупция һәм янап акча алу, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысу, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне бозу, шулай ук хезмәт урыныннан явызларча файдалану билгеләре булган башка гамәлләр кылу фактлары турында мәгълүматны ала.

20.3. Кергән мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, эшләнә торган яки хокукка каршы гамәл, шулай ук аны әзерли торган, эшли торган яки кылган зат турында мәгълүматлар булганда, мондый мөрәҗәгать аларның компетенциясе нигезендә хокук саклау органнарына җибәрелә.

20.4. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар, Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт мәгълүматларының һәм конфиденциаль характердагы белешмәләрнең сакланышы өчен билгеләнгән тәртиптә шәхси җаваплылык тоталар.

20.5. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе органнарның норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

## 21.Мөрәҗәгатьләр белән эшләү торышын тикшерү һәм аларны карап тикшерү. Мөрәҗәгатьләрдә булган мәгълүматны анализлау һәм гомумиләштерү

21.1. Органнар һәм вазыйфаи затлар үз компетенциясе чикләрендә мөрәҗәгатьләрне карау тәртибенең үтәлешен тикшереп торалар, килә торган мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеген анализлыйлар, гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу сәбәпләрен үз вакытында ачыклау һәм бетерү буенча чаралар күрә.

21.2.Һәр яртыеллык нәтиҗәләре буенча гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә һәм аларны карауга анализ ясала. Әлеге анализ буенча хисап Әлки муниципаль районының интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http:// http://alkeevskiy.tatarstan.ru/веб-адрес буенча урнаштырыла.

21.3. Авторга нәтиҗәләр турында җавап бирү таләп ителгән язма мөрәҗәгатьләр, шулай ук гражданнарны шәхси кабул итүдәге мөрәҗәгатьләр яисә тиешле орган яисә вазыйфаи зат таләбе буенча бирелгән барлык мәгълүмат үтәлү сроклары буенча тикшерелеп торырга тиеш.

21.4 Еллык хисап әзерләгәндә гражданнарның мөрәҗәгатьләре керүгә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатларында, гражданнар мөрәҗәгатьләре гомумиләштерә һәм анализлау уздырыла. Күрсәтелгән анализда кергән, янадан адресланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләр, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында мәгълүмат булырга тиеш.

21.5. Мөрәҗәгатьләр белән эшләүнең торышы (гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ) муниципаль район Башлыгының еллык хисабында чагыла һәм Интернет челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

## 22.Әлеге тәртипне бозган өчен җаваплылык.

22.1.Әлеге тәртипне бозуда гаепле затлар законнарда каралган җаваплылыкка ия.